**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г.Казань **БОЕРЫК**

21.10.2016 № 1155-п

Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Зур Сөлчә, Кече Сөлчә, Танай, Уратма, Шилнә елгаларының, Архирей һәм Ковалев күлләренең су саклау зоналарын һәм яр буе яклау полосаларын билгеләү турында

Россия Федерациясе Су кодексының 26, 65 статьялары, 2007 елның 24 июлендәге «Дәүләт күчемсез милек кадастры турында» № 221-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 10 гыйнварындагы «Җирлектә су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» № 17 карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 3 февралендәге «Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан дәүләт күчемсез милек кадастрына белешмәләр кертү өчен кирәкле документларны күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу, кадастр исәбенә алу һәм дәүләт күчемсез милек кадастрын алып бару өлкәсендә вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына җибәрү кагыйдәләрен раслау турында, шулай ук мондый документларның электрон рәвештәге форматына карата таләпләр турында» № 71 карары, Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2010 елның 29 сентябрендәге «Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан Россия Федерациясенең федераль милектәге һәм Россия Федерациясе субъектлары территориясендә урнашкан су объектларын яки аларның өлешләрен саклау чараларын гамәлгә ашыру буенча тапшырылган вәкаләтләрен башкару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» № 425 боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 06 июлендәге «Татарстан Республикасы Экология һәм табигый ресурслар министрлыгы мәсьәләләре» № 325 карары, 2016 елда су мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясенең аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясе субъекты бюджетына федераль бюджеттан субвенцияләр тапшыру турында 2016 елның 3 мартындагы № МТ-54/37 килешү нигезендә һәм 2016 елның 21 июнендәге «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү: Олы Сөлчә елгасы, Кече Сөлчә елгасы, Стәрле елгасы, Ютазы елгасы, Кичуй елгасы, Мораса елгасы, Сөлчә елгасы, Зур Бахта елгасы, Сөн елгасы, Кече

Чирмешән елгасы, Димескәй елгасы» № 16 МЭ-13Ф, 2016 елның 21 июнендәге «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зоналары чикләрен һәм яр буе яклау полосалары чикләрен билгеләү: Архирей (Тарлаш) күле, Ковал күле, Танай күле, Уратма елгасы, Шилнә елгасы, Бәрле елгасы, Норма елгасы, Урта Кабан күле, Түбән Кабан күле, Югары Кабан күле, Пөтке күле, Үләмә елгасы, Мохово күле» № 16 МЭ-14Ф Дәүләт контрактлары кысаларында башкарылган эш нәтиҗәләре буенча

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

2006 елның 3 июнендәге № 74-ФЗ Россия Федерациясе Су кодексының 65 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларының су саклау зонасы һәм яр буе яклау полосасы киңлеген бу чикләрдә башкарыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлекләрнең максус режимын исәпкә алып билгеләргә:

1.1. Зур Сөлчә елгасы:

Зур Сөлчә елгасының су саклау зонасы киңлеге – 200 м.

Зур Сөлчә елгасының яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3$^o$ ким булганда – 40 м; нульле яки капма-каршы авышлыкта булганда – 30 м.

1.2. Кече Сөлчә:

Кече Сөлчә елгасының су саклау зонасы киңлеге – 200 м.

Кече Сөлчә елгасының яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3 ким булганда – 40 м; нульле яки капма-каршы авышлыкта булганда – 30 м.

1.3. Архирей күле:

Архирей күленең су саклау зонасы киңлеге – 50 м.

Архирей күленең яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3$^o$ ким булганда – 40 м.

1.3. Ковалев күле:

Ковалев күленең су саклау зонасы киңлеге – 50 м.

Ковалев күленең яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3 ким булганда – 40 м.

1.4. Танай елгасы:

Танай елгасының су саклау зонасы киңлеге –100 м.

Танай елгасының яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3 ким булганда – 40 м.

1.5. Уратма елгасы:

Уратма елгасының су саклау зонасы киңлеге – 200 м.

Уратма елгасының яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3$^o$ ким булганда – 40 м; нульле яки капма-каршы авышлыкта булганда – 30 м.

1.6. Река Шильна:

Шилнә елгасының су саклау зонасы киңлеге – 100 м.

Шилнә елгасының яр буе яклау полосасы киңлеге: яр 3 һәм аннан күбрәк градуска авыш булганда – 50 м; яр авышлыгы 3 ким булганда – 40 м; нульле яки капма-каршы авышлыкта булганда – 30 м.

2. Хокукый тәэминат бүлегенә (М.Р. Галиәкбәров) бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына теркәүгә алу өчен җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Ф.С. Габделганиев